ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.03.2024 Олы Кайбы ав. № 95

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында муниципаль милек һәм Татарстан Республикасы дәүләт милке җирләрендәге гомуми файдаланудагы су объектларының сулык саклау зонасында ял итү рекреация зоналарын булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 04 августындагы 334 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районында муниципаль милек һәм Татарстан Республикасы дәүләт милке җирләрендәге гомуми файдаланудагы су объектларының сулык саклау зонасында ял итү рекреация зоналарын булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 04 августындагы 334 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 3.2. өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану Россия Федерациясе Су кодексының 50 статьясы нигезендә раслана торган рекреация максатлары өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен исәпкә алып, шулай ук су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы

Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров